| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ НОРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НОРМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«30» сентябрь 2024 ел № 113

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советының 2022 елның 27 июнендәге 57 номерлы “Мөлкәткә салым турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасының 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен, салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» Законына таянып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советының 2022 елның 27 июнендәге 57 номерлы “Мөлкәткә салым турында”гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Кодексның 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата (гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артып киткән административ-эшлекле һәм сәүдә үзәкләреннән (комплексларыннан) һәм эчендәге бүлмәләрдән тыш, әлеге Кодексның 378.2 статьясы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата, шулай ук һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган салым салу объектларына карата 2%;

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 2.6 пунктча белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән, гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артып киткән административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләре (комплекслар) һәм эчендәге бүлмәләргә карата 2025-2027 еллар чорына 1,2%;»;

1.3. 2.6 пунктчасын 3 пункт, 3 пунктны 4 пункт, 4 пунктны 5 пункт, 5 пунктны 6 пункт, 6 пунктны 7 пункт дип санарга.

2. Әлеге карарның гамәли көче 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көннән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Норма авыл җирлеге Башлыгы Р.Н. Шарипҗанов